ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 531-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Н.Н. Рыбушкин, А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 531-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 15 феврале
№ 2342-VI ДС

Проект
Татарстан
Республикасы Дәүләт
Советы депутатлары
Н.Н. Рыбушкин,
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кетрелә

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $6^1$ статьяда:

а) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, «Хәрби хәл турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел законга нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә хәрби хәл кертелгәндә, Татарстан Республикасы Рәисе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы территориясендә сайлаулар билгеләү турында тәкъдим җибәрергә хокуклы:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларга карата – тавыш бирү көненә кадәр иң күбе 105 көн һәм кимендә 95 көн кала;

2) җирле үзидарә органнарына сайлауларга карата – тавыш бирү көненә кадәр иң күбе 95 көн һәм кимендә 85 көн кала.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ һәм $5^2$ өлешләр өстәргә:

«$5^1$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 5 өлешендә каралган төрле дәрәҗәдәге сайлауларда тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта, сайлауларны билгеләү турындагы

тәкъдим югарырак дәрәҗәдәге сайлаулар өчен билгеләнгән сроклар дәвамында җибәрелергә тиеш.

$5^2$. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә, Татарстан Республикасы территориясенең бер өлешендә хәрби хәл кертелгән очракта, әлеге статьяның 5 өлешендә каралган сайлаулар билгеләнгән очракта, әгәр тиешле сайлау округы хәрби хәл кертелгән территорияне үз эченә алса, Татарстан Республикасы Рәисе хәрби хәл кертелгән көннән алып биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә тиешле сайлаулар үткәрү турында тәкъдим җибәрергә хокуклы.»;

в) 6 өлештә «әлеге статьяның 5 өлешендә каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «әлеге статьяның 5 өлешендә каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча яисә 52 өлешендә каралган, әмма тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

г) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 6 өлешендә каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 5 өлешендә каралган срокларны исәпкә алып, тиешле сайлауларны билгеләү турында (шул исәптән сайлау гамәлләре срокларын кыскарту мөмкинлеге белән) яисә Татарстан Республикасы Рәисенең аларны билгеләү хакындагы тәкъдимен кире кагу турында карар кабул итә, ә әлеге статьяның $5^2$ өлешендә каралган очракта, сайлаулар үткәрү турында йә хәрби хәл кертелгән Татарстан Республикасы территориясендә, Татарстан Республикасы территориясенең бер өлешендә сайлаулар үткәрү мөмкинлеге булмау турында кичекмәстән карар кабул итә.»;

д) 8 өлештә «, әлеге статьяның 7 өлешендә һәм әлеге Кодексның 6 статьясындагы 5 өлешендә билгеләнгән срокларны истә тотып,» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 9 өлештә «үткәрү турындагы» сүзләрен «билгеләү (үткәрү) турындагы» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 8 өлеше нигезендә сайлаулар билгеләнгәннән соң аларны әзерләү һәм үткәрү йә әлеге статьяның 52 өлеше нигезендә аларны үткәрү турында карар кабул итү Россия Федерациясе гражданнарының гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырса, тиешле сайлаулар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча кичектерелә, ул бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә.»;

з) 11 өлештә «кичектереп тору» сүзләреннән соң «(туктатып тору)» сүзләрен өстәргә, «5 – 8 өлешләрендә» сүзләрен «$5^2$ – 8 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга.

2) 10 статьяның 4 өлешендә «закон» сүзен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

3) 16 статьяның 6 өлешендә «Әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә төзелгән участок комиссиясенең вәкаләтләр чоры шул комиссия катнаша торган» сүзләрен «Әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә төзелгән участок комиссиясенең вәкаләтләр чоры якындагы сайлауларны билгеләү өчен әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 һәм 5 өлешләрендә каралган срокларда шул комиссия катнаша торган» сүзләренә алмаштырырга;

4) 17 статьяда:

а) 7 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 15 өлештә «4 – 7 һәм 10 өлешләрендә» сүзләрен «4 һәм 10 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

5) 18 статьяның 16 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасына, әлеге өлешнең беренче абзацында каралган түләүләрдән тыш, сайлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча сайлау комиссиясендә эшләгән өчен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 57 статьясындагы $3^1$ пункты нигезендә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән хезмәт өчен өстәмә түләү (бүләкләү) башкарылырга мөмкин. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 57 статьясындагы $3^1$ пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән хезмәт өчен өстәмә түләү (бүләкләү) күләмнәре һәм тәртибе Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

6) 22 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 өлеш өстәргә:

«10. Хәрби частьләрдә төзелгән сайлау участокларындагы тавыш бирү биналарында фотога һәм (яисә) видеога төшерү массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре тарафыннан 23 статьяның 3 өлеше нигезендә аккредитацияләнгән һәм тиешле хәрби часть командиры белән килештереп генә рөхсәт ителә.»;

7) 24 статьяның 3 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

8) 33 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле икенче – дүртенче абзацлар өстәргә:

«Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздырганда кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе иң күбе 15 вәкаләтле вәкил билгеләп куярга хокуклы.

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын сайлауларны уздырганда кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе иң күбе 5 вәкаләтле вәкил билгеләп куярга хокуклы.

Вәкаләтле вәкилләрнең гомуми саныннан кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе сайлау берләшмәсенең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләрен билгеләргә тиеш.»;

б) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5. Сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкилләре сайлауларны оештыручы комиссия тарафыннан әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән карар нигезендә теркәлергә тиеш. Сайлау берләшмәсенең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләре сайлауларны оештыручы комиссия тарафыннан әлеге статьяның 2 – 4 өлешләрендә каралган карар һәм нотариаль таныкланган ышанычнамә нигезендә һәм сайлау берләшмәсенең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле тарафыннан граждан паспорты яисә аны алмаштыручы документ күрсәтеп теркәлергә тиеш. Сайлау берләшмәсенең вәкаләтләре вәкилләрен теркәү әлеге статьяның 2 – 4 өлешләрендә күрсәтелгән документлар кергән көннән алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.».

в) 6 өлештә «туктатырга хокуклы» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә туктатырга хокуклы» сүзләренә алмаштырырга;

9) 45 статьяның 6 өлешендәге икенче абзацында «законда билгеләнгән срокта» сүзләрен «әлеге Кодекста билгеләнгән срокта» сүзләренә алмаштырырга;

10) 66 статьяда:

а) 4 өлештә «комиссияләр эшчәнлеген тәэмин итү өчен» сүзләрен «комиссияләр эшчәнлеген тәэмин итү, федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга ярдәм күрсәтү өчен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 12 өлештә «Сайлауларны әзерләүгә уздыруга бәйле товарлар, эшләр яисә хезмәтләр күрсәтү сатып алулар» сүзләреннән соң «, федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга ярдәм күрсәтүгә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла торган товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү сатып алуларны да кертеп,» сүзләрен өстәргә, «тиешле сайлауларны оештыручы комиссия яисә аның карары нигезендә түбәндәге тиешле» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 13 өлештә «Сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле товарларны, эшләрне яисә хезмәт күрсәтүләрне сатып алу» сүзләреннән соң «, федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга ярдәм күрсәтүгә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла торган товар, эш, хезмәт күрсәтү сатып алуны да кертеп,» сүзләрен өстәргә;

г) 14 өлештә «Сайлау кампаниясе уздыру чорында сайлау комиссияләренә тиешле дәрәҗәдәге сайлаулар әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән һәм агымдагы финанс елы ахырына Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте филиалларында ачылган счетларда булган Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары»

сүзләрен «Сайлау кампаниясе уздыру чорында сайлау комиссияләренә тиешле дәрәҗәдәге сайлаулар әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән һәм агымдагы финанс елы ахырына Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте филиалларында ачылган счетларда булган Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары, сайлау комиссияләренә федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга ярдәм күрсәтүгә бүлеп бирелгән һәм агымдагы финанс елы ахырына Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте филиалларында ачылган счетларда булган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары» сүзләренә алмаштырырга;

11) 67 статьяның 3 өлешендә «туктатырга мөмкин» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә туктатырга мөмкин» сүзләренә алмаштырырга;

12) 79 статьяда:

а) $6^1$ өлешнең алтынчы абзацында «, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә инанырга» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 өлештә «, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, башкарылган санауның дөреслеген тикшереп, шуңа ышанырга хокуклы» сүзләрен төшереп калдырырга;

13) 80 статьяда:

а) 11 өлештә «сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия беркетмә төзегән әгъзаларының,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 13 өлештә «үзенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 14 өлештә «тиешле комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 15 өлештә «үзенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

14) 83 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Закон нигезендә тиешле дәрәҗәдәге сайлаулар үткәрелгәндә, шул исәптән сайлаучыларны теркәгән (исәпкә алган), сайлаучылар исемлекләрен төзегән, сайлаучылар тавышларын санаган, тавыш бирү йомгакларын һәм сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләгән вакытта, «Сайлаулар» ДАСы файдаланылганда, тиешле сайлау комиссиясе «Сайлаулар» ДАСтан (аның кайбер техник чараларыннан) файдалануны тикшереп тору өчен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда, башка федераль законнарда каралган тәртиптә төркем төзи. Комиссиянең барлык әгъзалары, күзәтүчеләр «Сайлаулар» ДАСка кертелә торган һәм тавыш бирү йомгакларын, сайлаулар нәтиҗәләрен билгеләүгә бәйле рәвештә аннан чыгарыла торган теләсә кайсы мәгълүмат белән танышырга хокуклы.»;

15) 91 статьяның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) сәяси партияләрнең ышанычлы затларын һәм вәкаләтле вәкилләрен, шул исәптән сәяси партияләрнең финанс мәсьәләләре буенча ышанычлы затларын, вәкаләтле вәкилләрен терки, аларга билгеләнгән рәвештәге таныклыклар тапшыра;»;

16) 104 статьяның 2 өлешендә «тавыш бирү көненә билгеләнә алмаса» сүзләрен «якындагы тавыш бирү көненә билгеләнә алмаса» сүзләренә алмаштырырга, «бермандатлы сайлау округы буенча сайланган депутатның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән бер елдан да соңга калмыйча уздырылырга тиеш» сүзләрен «әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган киләсе тавыш бирү көненә йә күрсәтелгән тавыш бирү көненә кадәр башка көнгә, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга;

17)108 статьяның 1 өлешендәге 17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлау берләшмәләренең ышанычлы затларын һәм вәкаләтле вәкилләрен, шул исәптән сайлау берләшмәләренең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләрен терки, аларга билгеләнгән рәвештәге таныклыклар тапшыра;»;

18) 123 статьяның 2 өлешендә «тавыш бирү көненә билгеләнә алмаса» сүзләрен «якындагы тавыш бирү көненә билгеләнә алмаса» сүзләренә алмаштырырга, «бермандатлы сайлау округы буенча сайланган депутатның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән бер елдан да соңга калмыйча уздырылырга тиеш» сүзләрен «әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган киләсе тавыш бирү көненә йә күрсәтелгән тавыш бирү көненә кадәр башка көнгә, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $15^1$ статьяда:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Федераль закон нигезендә, «Хәрби хәл турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон нигезендә

хәрби хәл кертелгәндә, Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы референдумга чыгарыла торган мәсьәлә әлеге Законның 9 статьясы таләпләренә туры килүен таныган көннән алып биш көн эчендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы территориясендә референдум билгеләү турында тәкъдим җибәрергә хокуклы.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 4 пунктында каралган референдум билгеләнгәннән соң Татарстан Республикасы территориясендә, Татарстан Республикасы территориясенең бер өлешендә хәрби хәл кертелгән очракта, хәрби хәл кертелгән территория шушы референдум округына керә торган булса, Татарстан Республикасы Рәисе хәрби хәл кертелгән көннән алып биш көн эчендә, ләкин тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә референдум уздыру турында тәкъдим җибәрергә хокуклы.»;

в) 5 пунктта « әлеге статьяның 4 пунктында каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «әлеге статьяның 4 яисә $4^1$ пунктларында каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча,» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 5 пунктында каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе, әлеге Законның 15 статьясындагы 5 пунктында каралган срокларны исәпкә алып, референдум билгеләү турында яисә Татарстан Республикасы Рәисенең аны билгеләү турындагы тәкъдимен кире кагу хакында карар кабул итә, ә әлеге статьяның $4^1$ пунктында каралган очракта, кичекмәстән Татарстан Республикасы территориясендә, Татарстан Республикасы территориясенең хәрби хәл кертелгән өлешендә референдум уздыру турында йә референдум уздыруның мөмкин булмавы хакында карар кабул итә.»;

д) 7 пунктта «,әлеге статьяның 6 пунктында билгеләнгән срокларны истә тотып,» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 8 пунктта «үткәрү турындагы» сүзләрен «билгеләү (үткәрү) турындагы» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 7 пункты нигезендә референдум билгеләнгәннән соң йә әлеге статьяның $4^1$ пункты нигезендә аны уздыру турында карар кабул ителгәннән соң референдумны әзерләү һәм уздыру Россия Федерациясе гражданнарының гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырырга мөмкин булган очракта, референдум Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча кичектерелә, ул бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә.»;

з) 10 пунктта «кичектереп тору» сүзләреннән соң «(туктатып тору)» сүзләрен өстәргә, «4 – 7 пунктларында» сүзләрен «$4^1$ – 7 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

2) 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21 статья. **Референдум комиссиясен тарату**

1. Референдум комиссиясе Федераль законның 31 статьясында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә таратылырга мөмкин.»;

3) 22 статьяга түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:

«15. Хәрби частьләрдә төзелгән референдум участокларындагы тавыш бирү урыннарында фотога һәм (яисә) видеога төшерү бары тик әлеге статьяның $11^2$ пункты нигезендә аккредитацияузган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре тарафыннан һәм тиешле хәрби часть командиры белән килештереп кенә рөхсәт ителә.»;

4) 58 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Референдум уздырганда, шул исәптән референдумда катнашучыларны теркәгәндә (исәпкә алганда), референдумда катнашучылар исемлекләрен төзегәндә, референдумда катнашучылар тавышларын санаганда, тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә һәм референдум нәтиҗәләрен ачыклаганда закон нигезендә «Сайлаулар» ДАСтан (аның аерым техник чараларыннан) файдаланганда, тиешле референдум комиссиясе Федераль законда каралган тәртиптә «Сайлаулар» ДАСтан (аның аерым техник чараларыннан) файдалануны тикшереп тору өчен төркем төзи. Референдум комиссиясенең барлык әгъзалары, күзәтүчеләр «Сайлаулар» ДАСка кертелә торган һәм тавыш бирү йомгакларын, референдум нәтиҗәләрен билгеләүгә бәйле рәвештә аннан алына торган теләсә нинди мәгълүмат белән танышырга хокуклы.».

**3 статья**

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $18^1$ статьяда:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, «Хәрби хәл турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон нигезендә хәрби хәл кертелгәндә, Татарстан Республикасы Рәисе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы референдумга чыгарыла торган мәсьәлә әлеге Законның 10 статьясы таләпләренә туры килүен

таныган көннән алып биш көн эчендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә референдум билгеләү турында тәкъдим җибәрергә хокуклы..»;

б) түбәндәге эчтәлекле 4[1] пункт өстәргә:

«4[1]. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 4 пунктында каралган референдум билгеләнгәннән соң Татарстан Республикасы территориясендә, Татарстан Республикасы территориясенең бер өлешендә хәрби хәл кертелгән очракта, хәрби хәл кертелгән территория шушы референдум округына керә торган булса, Татарстан Республикасы Рәисе хәрби хәл кертелгән көннән алып биш көн эчендә, ләкин тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә референдум уздыру турында тәкъдим җибәрергә хокуклы.»;

в) 5 пунктта « әлеге статьяның 4 пунктында каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «әлеге статьяның 4 яисә 4[1] пунктында каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 5 пунктында каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе, әлеге Законның 18 статьясындагы 6 пунктында каралган срокларны исәпкә алып, референдум билгеләү турында яисә Татарстан Республикасы Рәисенең аны билгеләү турындагы тәкъдимен кире кагу хакында карар кабул итә, ә әлеге статьяның 4[1] пунктында каралган очракта, кичекмәстән Татарстан Республикасы территориясендә, Татарстан Республикасы территориясенең хәрби хәл кертелгән өлешендә референдум уздыру турында йә референдум уздыруның мөмкин булмавы хакында карар кабул итә.»;

д) 7 пунктта «, әлеге статьяның 6 пунктында билгеләнгән срокларны истә тотып,» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 8 пунктта «үткәрү турындагы» сүзләрен «билгеләү (үткәрү) турындагы» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 7 пункты нигезендә референдум билгеләнгәннән соң йә әлеге статьяның 4[1] пункты нигезендә аны уздыру турында карар кабул ителгәннән соң референдумны әзерләү һәм уздыру Россия Федерациясе гражданнарының гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырырга мөмкин булган очракта, референдум Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча кичектерелә, ул бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә.»;

з) 10 пунктта «кичектереп тору» сүзләреннән соң «(туктатып тору)» сүзләрен өстәргә, «4 – 7 пунктларында» сүзләрен «4[1] – 7 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

2) 24 статьяга түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:

«15. Хәрби частьләрдә төзелгән референдум участокларындагы тавыш бирү урыннарында фотога һәм (яисә) видеога төшерү бары тик әлеге статьяның $11^2$ пункты нигезендә аккредитация узган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре тарафыннан һәм тиешле хәрби часть командиры белән килештереп кенә рөхсәт ителә.».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга һәм «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 14 ноябрендәге 531-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә әзерләнде һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексын, «Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы һәм «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарын күрсәтелгән федераль законга туры китерүгә юнәлдерелә.

Закон проекты сайлаулар уздыру тәртибенә, хәрби хәл кертелгәндә референдум уздыру тәртибенә, участок комиссияләрен төзү тәртибенә, сайлауларны әзерләгәндә һәм уздырганда, товарлар, эшләр яисә хезмәт күрсәтүләр сатып алу тәртибенә, сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасына хезмәтенә өстәмә түләү (бүләкләү) мәсьәләләренә һәм башкаларга үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

Аерым алганда, закон проекты белән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны әзерләү һәм уздыру өчен ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бүлеп бирү хокукы карала. Сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасына сайлауларны әзерләү һәм уздыру буенча башкарган хезмәте өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә торган күләмдә һәм тәртиптә өстәмә түләү (бүләкләү) мөмкинлеге бирелә. Күрсәтелгән акчаларны тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуга файдалану хокукы билгеләнә.

Закон проектында хәрби частьләрдә төзелгән сайлау участокларындагы тавыш бирү урыннарында фото- һәм (яисә) видеога төшерү аккредитация узган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре тарафыннан гына һәм тиешле хәрби часть командиры белән килештереп кенә рөхсәт ителү беркетелә.

Моннан тыш, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында закон проектында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына сайлауларны уздырганда сайлау берләшмәләренең вәкаләтле вәкилләре саны билгеләнә.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.